**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2015 Балык Бистәсе штп. № 356пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында ГТО комплексының сынау (тестлар) нормативларын үтәү буенча тест үзәкләрен булдыру турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законның 9,9.1, 31.2 статьялары нигезендә., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 11 июнендәге 540 номерлы карары белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы турындагы Нигезләмәнең 26 пункты, Россия Федерациясе спорт министрлыгының "Нормативлар, сынау (тест) төрләрен үтәү буенча тест үзәкләрен булдыру, физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләр Тәртибен һәм алар турында Нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 1 декабрендәге 954/1 номерлы боерыгы, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы, «Татарстан республикасында ГТО комплексын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 4 сентябрендәге 1763-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында түбәндәге коммерциячел булмаган оешмалар базасында ГТО комплексының сынау (тестлар) нормативларын үтәү буенча тест үзәкләрен булдырырга:

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Дельфин" спорт – сәламәтләндерү комплексы» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба - «Дельфин ССК" МБУ);

1.2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балалар – яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба-«ДЮСШ»).

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында ГТО комплексының сынау (тестлар) нормативларын үтәүне бәяләү буенча түбәндәге коммерциячел булмаган оешмаларга хокук бирергә:

2.1. МБУ " СОК «Дельфин»;

2.2. МБУ "ДЮСШ".

3. Җитәкчеләр итеп билгеләргә:

3.1.1.«СОК "Дельфин" МБУнең тест үткәрү үзәге - "СОК Дельфин" МБУ директоры Имамов Рәдис Хәсән улын;

3.1.2.«ДЮСШ» балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбенең тест үткәрү үзәге - Мәгыйзов Марс Венер улын «ДЮСШ балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе" директоры;

3.2. Баш судьялар итеп билгеләргә:

3.2.1.МБУ "СОК Дельфин" тестлау үзәге- «Балалар сәламәтләндерү-белем бирү (профильле) үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директоры Гиннатуллин Илнур Ибраһим улын;

3.2.2. МБУ “ДЮСШ” тестлау үзәге-Смолин Андрей Владимирович – «ДЮСШ» балалар–яшүсмерләр спорт мәктәбенең инструктор-методисты.

4.Үз эшчәнлекләрендә тестлау үзәкләре Россия Федерациясе спорт министрлыгының "Нормативлар, сынау (тест) төрләрен үтәү буенча тест үзәкләрен булдыру, физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләр Тәртибен һәм алар турында Нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 1 декабрендәге 954/1 номерлы боерыгы белән расланган нормативлар, физик культура һәм спорт өлкәсендәге белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләр һәм нигезләмә белән таяналар.

5.«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләр нормативларын, тест төрләре (тестлар) үтәү буенча тест үзәкләрен төзү турында»Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 22 июнендәге 178пи номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.

6. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин